| | | |
|---|---|---|
| **РАСЛЫЙМ** | **РАСЛЫЙМ** | **РАСЛЫЙМ** |
| Россия ислам институты ректоры<br>Р.М. Мөхәммәтшин | Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы Диния нәзарате Мөфтие<br>К.И. Сәмигуллин | «Идел» журналы баш мөхәррире<br>Г.Р. Закирова |

## «Таян Аллаһка» әдәби конкурсының НИГЕЗЛӘМӘСЕ

### I. Конкурсның гомуми нигезләмәләре

**1.1.** «Таян Аллаһка» әдәби конкурсы Россия Федерациясендә яшәүче татарлар арасында талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатында уздырыла.

Конкурсның бурычлары:

– сәләтле яшьләргә, башлап язучыларга иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;

– татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм ислам динен пропагандалау.

Оештыручылар:

«Идел» журналы, Россия ислам институты, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарате.

**1.2.** Вакыты һәм үткәрү тәртибе

Конкурс өч этапта үтә:

1 этап – әсәрләрне кабул итү (1 февраль – 31 июль).

2 этап – әсәрләрне жюри тарафыннан бәяләү (август).

3 этап – җиңүчеләрне бүләкләү (сентябрь).

### II. Конкурста катнашу шартлары

**2.1.** Конкурста Россия Федерациясендә яшәүче 10 яшьтән 60 яшькә кадәрле һәрбер теләгән кеше катнаша ала.

**2.2.** Конкурс иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәүчеләр өчен үткәрелә, профессиональ язучыларның, шагыйрьләрнең, журналистларның әсәрләре һәм язмалары кабул ителми.

**2.3.** Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләр һәм мәкаләләр **әдәби татар телендә** языларга тиеш.

**2.4.** Конкурс номинацияләре:

- шигърият;
- чәчмә әсәр;
- публицистик язма.

**2.5.** Аз күләмле әсәрләр (шигырьләр, кыска хикәяләр һ.б.) һәм публицистик язмаларның саны өчтән дә ким булмаска тиеш. Аларны түбәндәге таләпләргә туры китереп эшләргә кирәк: Times New Roman шрифтында, 14 нче кегль, бер ярым интервалда, сул яктан – 30 мм, уң яктан – 10 мм, өстән – 25 мм, астан – 20 мм.

**2.6.** Авторлар эшләрен өч номинациянең берсенә генә җибәрә ала, ягъни бер автор бары бер генә номинациядә катнаша ала.

**2.7.** Конкурска язмалар электрон вариантта кабул ителә. Конкурс материалларын җибәрү өчен электрон адрес: tatarkonkurs@mail.ru.

**2.8.** Әсәрләр белән бергә конкурста катнашучы үзе турында кыскача мәгълүмат, адресын һәм телефон номерын җибәрергә тиеш. Конкурска җибәрелгән материалларны алып теркәгәннән соң, оештыру комитеты авторларның электрон почтасына раслау җибәрә. Конкурс белән бәйле барлык мәгълүматлар да оештыручыларның рәсми сайтларында урнаштырылачак.

## III. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

**3.1.** Конкурста катнашучыларның әсәрләрен анализлау һәм бәяләү өчен оештыру комитеты тарафыннан махсус комиссия (жюри) билгеләнә.

**3.2.** Комиссия, конкурска килгән язмаларны тикшереп, һәр номинациядә беренче, икенче, өченче урыннарны билгели. Моннан тыш, Гран-при, махсус бүләкләр булуы да мөмкин.

Жюри Гран-при һәм призлы урыннарны бирмәү хокукына да ия.

Конкурс нәтиҗәләре буенча лаеклы дип табылган әсәрләр «Идел» журналы битләрендә урын алачак.

Оештыру комитеты адресы: Казан ш., Газовая урамы, 19 нчы йорт. Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы. E-mail: tatarkonkurs@mail.ru

Белешмәләр өчен телефон: 8(843)2776826.